ТАТАСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Югары Колчурино авыл җирлеге
башкарма комитеты

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Верхнеколчуринского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

Адресы: 422873, РТ, Әлки районы, Югары
Колчурино авылы, 8 Март ур., 21
Телефон (84346)78014

Адрес: 422873, РТ, Алькеевский район,
с. Верхнее Колчурино, ул. 8 Марта, д. 21
Телефон (84346) 78014

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 19 августы 23№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Югары Колчурино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчурино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 маендагы 7 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Югары Колчурино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре»нә (2016.13.12, редак. үзгәрешләр һәм өстәмәләр)1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru/ сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчуринор авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Югары Колчурино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Краснова

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Югары Колчурино
авыл җирлеге Советының 2021 елның
19 августындагы 23 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Югары Колчурино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.**

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 маенда 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Югары Колчурино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016.13.12, 7№ редак.) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

35 статья 3 кисәктә зоналарда:

**ТБ (торак бина)1 перспектив торак төзелеше зонасы:**
1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 нче таблица

| Параметр төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Көчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы гаилә йорты | 2 фатирдан артык булмаган кишәрлекле блокланган йортлар |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | **1000** | **1000** |
| Урам буйлап минималь киңлек (үтү) | м | 15 | 12 |
| **Җир кишәрлекләре чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кишәрлекләр төзелешенең максималь проценты | % | 45 | 55 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (төзелешне җайга салу сызыгы башка күрсәткеч белән билгеләнмәгән очракта) | м | 3 | 3 |
| Кишәрлекнең ян чигеннән корылмаларның минималь чигенеше | м | а) 1-брандмауэр дивар мәҗбүри булганда;<br>б) 3-башка очракларда | а) 0-күрше блокларга кушылган очракларда;<br>б) 3-башка очракларда |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (төзелешне җайга салу линиясенең башкасы билгеләнмәгән булса) | м | 3 | 3 |
| Корылмаларның максималь биеклеге | м | 12 | 12 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2 | 2 |

* Таблицага искәрмә:
Җир кишәрлекләренең ян һәм арткы чикләреннән түбәндәге шартларда корылмаларның чигенү таблицасында бирелгән чигенешләрдән тайпылышлар рөхсәт ителә:
-җир кишәрлекләре хуҗаларының күрсәтелгән тайпылышларга үзара ризалыгы булу;
- төп корылмалар (торак йортлар) арасындагы ераклык 6 метр яки артып китә, ә ярдәмче корылмалар (хуҗалык корылмалары, гаражлар һ.б.) арасындагы ераклык 2 метр яки артып китә.( шулай ук ярдәмче корылмаларны блоклау рөхсәт ителә);
- күрше җир кишәрлекләрендә урнашкан корылмалар арасында янгынга каршы норматив ераклык саклана.